ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.04.2019 Алексеевск ш.т.б № 150

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында**

Һөнәри керемгә салым буенча салым потенциалы үсешен стимуллаштыру максатларында

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы Тәртипне расларга (Кушымта).
2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе О. Н. Леденцовка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы** **Н.П. Чурин**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
11.04.2019 № 150
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар (алга таба – башка бюджетара трансфертлар, муниципаль берәмлекләр) бирү механизмын билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасында профессиональ керемгә салым салу буенча һәм салым потенциалы үсешен стимуллаштыру максатларында Алексеевск муниципаль районы җирлекләре бюджетларына җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә бирелә;

3. Башка бюджетара трансфертлар, тиешле финанс елына һәм план чорына, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджеты турындагы карарында күрсәтелгән максатларга каралган бюджет ассигнованиеләре күләме чикләрендә, узган кварталдан соң килүче айның 30 числосына кадәр җирлекләр бюджетына бирелә.

4. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчаларын төп бүлүче булып Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы (алга таба – финанс-бюджет Палатасы) тора.

5. Башка бюджетара трансфертларны бүлү Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

6. i муниципаль берәмлегенең тиешле кварталга башка бюджетара трансфертлары күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$МТ_i^{кв} = НПД_i^{ел} – НПД_i^{пт},$$

монда:

$МТ_i^{кв}$ – тиешле квартал өчен i муниципаль берәмлегенә башка бюджетара трансфертлар күләме, сум;

$НПД_i^{ел}$ – Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә теркәлгән салым түләүчеләрдән ел башыннан бирле арта торган нәтиҗә белән i муниципаль берәмлек территориясеннән Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджетына кергән һөнәри керемгә салым суммасы, сум акча;

$НПД_i^{пт}$ – Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә теркәлгән салым түләүчеләрдән, элек башка бюджетара трансфертлар бирү максатларында исәпкә алынган салым түләүчеләрдән, i муниципаль берәмлек бюджетына салым түләүчеләрдән кергән һөнәри керемгә салым суммасы, сум күләмендә.

7. Муниципаль район составына керүче җирлекләрнең бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү шарты – җирлекнең башка бюджетара трансфертлар акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган чыгымнарның юнәлешен билгели торган норматив хокукый акты булу.

8. Башка бюджетара трансфертлар финанс-бюджет палатасы тарафыннан җирлекләр бюджетларына җирле бюджетларның үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен ачылган Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең территориаль органнары счетына күчерелә.

9. Җирлекләрнең башкарма комитетлары (алга таба – җирлек башкарма комитетлары) финанс-бюджет палатасына форма буенча һәм финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап тапшыралар.

10. Әлеге Тәртип нигезендә алынган башка бюджетара трансфертлар агымдагы финанс елның 1 гыйнварына кадәр файдаланылмаганда, агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджеты керемнә кире кайтарылырга тиеш.

Әлеге башка бюджетара трансфертларның калдыкларыннан артмаган күләмдәге акчалар финанс-бюджет палатасының хисап финанс елында файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булу турындагы карары нигезендә, моңа кадәр бирелгән җирлек бюджеты керемнә агымдагы финанс елында, башка бюджетара трансфертларны бирү максатларына туры килә торган җирлек бюджеты чыгымнарын финанс ягыннан тәэмин итү өчен, кире кайтарылырга мөмкин.

Әлеге Тәртип нигезендә алынган башка бюджетара трансфертларның файдаланылмаган калдыклары Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджеты керемнә күчерелмәгән очракта, әлеге акчалар Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджеты керемнә алынырга тиеш.

11. Җирлекләрнең башкарма комитетлары һәм вазифаи затлары законнар нигезендә тапшырыла торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын үтәү өчен җаваплы.

12. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары бозылган очракта, тиешле акчалар Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджеты керемнә Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә күчерелергә тиеш.

13. Әлеге Тәртип нигезендә бирелгән башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын контрольдә тотуны финанс-бюджет палатасы гамәлгә ашыра.